Проект эше

# Рус телендә сөйләшүче балаларга ФДББС шартларында татар теле һәм әдәби уку дәресләрендә уен технологиясе элементларын куллану

***“Уен – әйләнә-тирә мохит төшенчәләрен баланың рухи дөньясына алып керүче зур якты тәрәзә ул. Уен-кызыксыну һәм белемгә омтылу утын кабыза торган учак ул”,-ди***

***В.А. Сухомлинский.***

Дәресләрдә урынлы кулланылган уеннар укучыларны активлаштыра, аларның игътибарын дәрес материалына юнәлтә һәм иҗади халәт булдыра. Уеннар вакытында фән нигезләрен үзләштерү белән бергә укучы үз фикерләрен дәлилли белү күнекмәләре дә ала. Шулай итеп, уеннар бала тормышында әһәмиятле урын алып торалар, белем һәм тәрбия бирүдә мөһим чыганак булалар.

Югарыда китерелгән фикерләр проект эше темасының **актуальлеген** дәлилли.



Проект эшебезнең **максаты** – татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә рус телендә сөйләшүче укучыларны татар телендә аралашырга өйрәтүдә уеннарның әһәмиятен күрсәтү.

Максатыбызга ирешү өчеу түбәндәге **бурычлар** куелды:

- уеннарның укыту процессында тоткан ролен ачыклау;
- укучыларның коммуникатив компетенциясен үстерү максатыннан кулланылган уеннарны ачыклау.



**Тикшеренү объекты** – рус телендә сөйләшүче укучыларның коммуникатив компетенциясен үстерүдә уен технологиясенең элементлары кулланылышы.

**Тикшеренү предметы** – татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә кулланылган уен технологиясе элементлары.

**Метод һәм алымнар**. Өйрәнелә торган материалның характерына карап, тикшеренүнең төп методы булып күзәтү методы сайланды. Әлеге метод үз эченә фәнни һәм методик әдәбиятны туплау һәм анализлау, фактик материалны өйрәнү, педагогик тәҗрибәне гомумиләштерү, классификацияләү кебек эш алымнарын берләштерә.



Хәзерге заман таләпләренә туры килә торган белем бирү шәхесне җәмгыятьтәге төрле үзгәрешләргә, тормыш сынауларына, фән нигезләрен ныклы үзләштерүгә әзерләүне күздә тота. Заманча технологияләр кулланып татар телен өйрәтү – уку-укыту процессын яңача оештыру ул. Ул түбәндәге максатларны күздә тотып башкарыла:

татар телен өйрәнүгә кызыксындыру, теләк уяту

укучыларның танып белү активлыгын арттыру

телне өйрәнү өчен уңай шартлар булдыру

укучыларның иҗади мөмкинлекләрен тулырак ачу

# <u>***УЕННАР***</u>

**интеллектуаль уеннар**

**психологик уеннар**



**хәрәкәтле уеннар**

**иҗтимагый уеннар**



Яңа гына балалар бакчасыннан килгән сабыйларның игътибарлары да, истә калдыру сәләте дә бик йомшак, бигрәк тә уку кызыклы булмаса.

Баланың мәктәпкә кергәндә барлыкка килгән психологик киртәләрне тиз арада җиңү юлы итеп укыту-тәрбия процессында уеннар, аның элементларын куллану бик отышлы.



Педагогик эшчәнлеккә бәйле рәвештә түбәндәге уен төрләрен аерып күрсәтергә мөмкин: дидактик уеннар (бу төр уеннар укучыларда белем-күнекмәләр формалаштыруга һәм камилләштерүгә, танып-белү эшчәнлеген киңәйтүгә юнәлтелгән), тәрбияви уеннар, иҗади уеннар, коммуникатив уеннар. Үткәрү методикасы буенча уеннар бик күп төрләргә бүленә: предметлы уеннар, сюжетлы уеннар, рольле уеннар, эшлекле уеннар һ.б.

**Укытуның башлангыч этабында кулланылучы фонетик уеннар арасыннан уен-табышмак, уен-имитация, уен-ярыш, предметлар белән уеннар, игътибарлыкка уеннарны аерырга мөмкин. Дөрес әйтүгә өйрәткәндә чираттагы уеннар файдалы.**




- **«Кызык телефон» уены**
- Тактада зур телефон рәсеме ясала. Дискта саннар урынына хәрефләр языла. Укучылар билгеле вакыт аралыгында күбрәк итеп (специфик татар авазларын кулланып) сүзләр җыярга һәм аларны әйтергә тиешләр. *Мәсәлән, әни, һәм, кар, өстәл, үрдәк, чәйнек, чиләк, җиләк һ. б.*

## Лексик уеннар

Лексикага өйрәткәндә карточкадагы уеннар, табышмаклар, кроссвордлар, чайвордлар, «Сүзне тап», «Мәкальне тап» кебегрәк уеннар куллану кулайрак була.

Укытучы уенны: *«Бүген без сезнең белән авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә барабыз. Анда иң яхшы каз, тавык, күркә төрләрен күргәзмәгә куйганнар. Бүген без нәрсә теләсәк, шуны сатып ала алабыз; кошның бәясе – җөмлә. Кем күбрәк әйтсә, шул сатып ала. Беренче булып каз сатыла»*, – дип башлый. Укучылар: *«Бу – каз. Каз ак, шаян. Каз ит бирә, мамык бирә. Каз солы ярата, үлән ашый. Казның бәбкәләре була»*.

Ахыргы җөмләне әйткән кешегә каз бирелә. Бу уенда теләсә-кайсы укучы җиңүче була ала.

Тизлеккә булган лексик уеннар да әһәмиятле (укучылар бирелгән сүзләргә тиңдәш яки капма-каршы мәгънәле сүзләрне; әлеге сүзтезмәләрдә кулланырга мөмкин булган сүзләрне мөмкин кадәр тизрәк әйтергә тиеш булганда).



# Диалогик һәм монологик сөйләмгә өйрәтү уен элементлары

Диалогик сөйләмгә өйрәтү һәрбер дәрестә дә булырга тиеш. Укучыларның әлеге сөйләм төренең көндәлек тормышта кирәклеген тоюы мөһим. Барлык лексик-грамматик материал диалоглар һәм аралашу ситуацияләре аша үзләштерелә.

**“Ел фасыллары” уены.** Укытучы укучыларга ел фасыллары һәм бердән алып уникегә кадәр санар язылган карточкалар тарата. Укучылар бу карточкаларны бер-берсенә күрсәтмәскә тиеш. Укучылар басалар. Һәр ел фасылы үзенә туры килгән айларны табып, команда булдырырга тиеш. Кайсы команда тизрәк җыела, шул җиңүче. Моның өчен алар кулларын күтәреп парлашалар, сораулар бирәләр: “Син нинди ай?” “Син кышмы?”.Барлыкка килгән командалар үзләре белән таныштыралар.


зима
декабрь
январь
февраль
весна
март
апрель
май
лето
июнь
июль
август
осень
сентябрь
октябрь
ноябрь
°C
жарко
тепло
холодно



# «Эстафета» уены

- Укучылар ике рәткә басалар. Укытучы «башладык» диюгә, беренче укучы, тәкъдим ителгән темага караган сүз әйтеп, таякны иптәшенә тапшыра, анысы – икечесенә. Эстафета таягы финишка алданрак барып җиткән төркем җиңүче була. Бу уенны санарга өйрәткәндә дә уйнарга мөмкин. Бердән унга һәм киресенчә – уннан бергә кадәр саный-саный, балалар таякны бер-берсенә тапшыралар

Түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

– рус балаларына татар телен өйрәтүдә уеннар куллануның әһәмияте бик зур, алар үзләштерелүче материалны җиңеләйтә һәм чит телне өйрәнү процессын күңелле итә;

– уеннарын һәм аларның куллану закончалыкларын тикшереп, анализлап без рус телле укучыларга чит тел буларак татар телен өйрәтү процессында аларның алыштыргысыз роль уйнауларына инандык. Нәкъ менә уенда баланың иҗади мөмкинлекләре ачыла һәм яхшыртыла. Уен әйләнә-тирә дөньяны танып белергә өйрәтә;

– тел уеннарының 8 төре бар.



# ИГЪТИБАРЫГЫЗ ӨЧЕН РӘХМӘТ!